ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, 5, с.Бишня, 422528

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БИШНӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 5, Бишнә ав., 422528

Тел./факс: (84371) 6-46-10. E-mail: Bsn.Zel@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 7 ноябре с.Бишня № 30

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.01.2021 ел, №2 карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (10.09.2020 ред.), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты,

**КАРАР ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитетының 25.01.2021 ел, №2 карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә, аны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Халык җыены карары белән муниципаль берәмлек (торак пункт (яисә аның территориясе өлеше) гомуми санынан 30 проценттан артып китә алмаган гражданнарның аерым категорияләре билгеләнә, алар өчен түләүләр күләме киметелергә мөмкин.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай

ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы:** **И.М.Фатхуллин**